ГЛАВА СРЕДНЕКИРМЕНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Ленина, д.16А, с. Средние Кирмени,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422171

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ УРТА КИРМӘН АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Ленин ур., 16А нчы йорт, Урта Кирмән авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422171

тел.(факс): (85563) 2-92-38;2-92-44 e-mail: Skimer.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Постановление | Карар

“28 ” ноябрь 2022 ел | № 5

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Урта Кирмән авыл җирлегенең Арташ торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» гы 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Урта Кирмән авыл җирлеге муниципаль берәмлеге” Уставының 23 статьясы нигезендә карар бирәм :

1.Татарстан Республикасы, Мамадыш муниципаль районы, Арташ авылы, Киров урамы 27 йорт адресы буенча урнашкан Арташ авылы клубы бинасында 2022 елның 12 декабрендә сәгать 10.00 гә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Урта Кирмән авыл җирлеге Арташ торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү.

2.Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2022 елда җыелган гражданнарның калган үзарасалым акчаларын түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтергә ризамы:

- Арташ торак пунктында су алу скважинасын ремонтлау (скважинаны чистарту, юдыру, килешү буенча эш өчен түләү),Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Урта Кирмән авыл җирлеге бюджетына 12.11.2021 ел, № 2 “Мамадыш муниципаль районының Урта Кирмән авыл җирлеге составына керүче Арташ торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм файдалану мәсьәләсе буенча" гражданнар җыены карарына ярашлы рәвештә кергән 215 000 (ике йөз унбиш мең) сум күләмендәге үзарасалым акчасын алдагы җирле әһәмияттәге мәсьәләне хәл итү өчен тотылуына сез ризамы:

- Карл Маркс урамыннан Арташ торак пункты зиратына кадәр юлга вак таш җәю (сатып алу, ташу, ком салу, вак таш салу, килешү буенча эшләр өчен түләү)

« ӘЙЕ» «ЮК».

3. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Урта Кирмән авыл җирлеге башкарма комитетына Арташ торак пунктында гражданнар җыенын оештыруны һәм уздыруны йөкләргә .

4. Әлеге карарны кабул иткәннән соң 3 көн эчендә муниципаль берәмлек Советының мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) сайтында урнаштырырга.

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Урта Кирмән авыл җирлеге башлыгы: Б.Ф.Хасанов